Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Тукай районы буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Тукай районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 109-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Тукай районы буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Тукай муниципаль районының Әҗмәкәй, Боерган, Калмаш, Калмия, Князево, Күзкәй, Кече Шилнә, Сәмәкәй, Иске Абдул, Теләнче-Тамак, Шилнәбаш һәм Яңа Бүләк авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Тукай муниципаль районының Бәтке, Биклән, Борды, Иштирәк, Комсомолец, Круглое Поле, Мәләкәс, Мусабай-Завод, Түбән Суыксу, Яңа Троицкий һәм Иске Дөреш авыл җирлекләре.